ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 14 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), «, ләкин 10 елдан күп булмаган вакытка» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына

(Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «салым ставкасы» сүзләреннән соң «, әлеге статьяда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә;

2) 2 өлештә «2025 елга кадәр (бу елны кертеп)» сүзләрен «махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогына» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 өлештә «, 2» санын төшереп калдырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы, махсус инвестиция контракты төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында башкарыла торган эшчәнлектән алынган керемнәрнең (тотылган чыгымнарның) һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда алынган керемнәрнең (тотылган чыгымнарның) исәбен аерым алып бару шарты белән, күрсәтелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында башкарыла торган эшчәнлектән салым базасына карата кулланыла.»;

5) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 21 июнь
№ 37-ТРЗ